**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«01» ноябрь, 2024 ел Иштирәк авылы № 5

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлеге Уставы, Иштирәк авыл җирлеге Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының 08.11.2019 ел «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Иштирәк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «Нигезләмәне раслау хакында»52/1 номерлы" карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2024 елның 16 ноябренә 12.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. . Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау Үзәк урамында).

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Аулаш авылы, Үзәк урам, 67/1 (ФАП бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы Г.С. Гарифуллина